.



XXIVнче “Солә́йманов укулары- 21» кысаларында ике чара булып vтте: 28 майда - фәнни-гамәли конференция, 29 майда - тvгәрәк остәл.

Фәнни-гамәли конференциянен темасы: “ Дәvләт милли сәясәте Стратегиясе кысаларында себер тараларынын һәм Томән олкәсендә яшәvче татарларнын телен, мәдәниятен, тарихи мирасын саклау һәм vстерv момкинлекләре”.

28 майда конференция 28 майда олкә фәнни китапханәсендә vтте, аны олкә Хакимиятенен Милли эшләр комитеты финанслады,

оштыручылар исемлеге шактый зур булып чыкты:

Томән олкәсе Милли эшләр комитеты,

олкә Мәгариф департаменты,

Томән олкәсе Думасы,

Д.И.Менделеев исемендәге олкә фәнни китапханә,

Төмән олкәсенен себер татарлары һәм олкә татарлары милли-мәдәни мохтәрияте,

Төмән шәһәренен “Себер татарлары” милли-мәдәни мохтәрияте,

Төмән шәһәренен Татар мәдәнияте vзәге.

Конференциядә олкә Хакимиятенен Мәгариф департаменты житәкчесе Райдер Алексей Владимирович, олкә Җәмәгать пулаты рәисе урынбасары һәм Милли-мәдәни мохтәриятләрнен Координацион шурасы рәисе Вообьев Евгений Михайлович, Милли эшләр комитеты рәисе Чернов Владислав Леонидович, олкә моселманнары Диния нәзарәте рәисе – мофти Зиннәт хәзрәт Садыйков һәм башка шәрәфле кунаклар булды.

Президиумда - Төмән дәvләт университеты профессоры, Тюркология vзәге житәкчесе, филология фәннәре докторы Хәнисә Чәvдәт кызы Алишина, Төмән шәһәренен “Себер татарлары милли-мәдәни мохтәрияте” рәисе, конференцияне оештыру комиссиясе житәкчесе Динар Марсель улы Абукин, тарих фәннәре кандидаты, Россия фәннәр академиясенен Тубылдагы фәнни станциясе олкән фәнни хезмәткәре

Тычинских Зәйтvнә Әбдерәшит кызы, филология фәннәре докторы,

Россия Эчке эшләр министрлыгынын

Төмән бvлекчәсе хезмәткәрләренен квалификациясен vстерv институты профессоры

Шагбанова Хәбибә Садыйр кызы.

Конференцияне Динар Абукин алып барды, рәисдәше Хәнисә Алишина иде. Кереш котлау сvзен динар Абукин Булат Соләйманов шигыреннән бер озекне сәнгатьле янгыратуы белән башлап жибәреп, бу чаранын бәйрәм рухын кабызып жибәрде. Россиянен коче – милләтләр бердәмлегендә, һәм милләтнен vсеше дәvләткә коч-куәт ости, дигән фикерне ачыклап сойләде, Булат Солэймановнын якты истәлеге милли vсеш хәрәкәте юлларын яктыртып торуын ачыклап кvрсәтте Динар әфнде. Төмән олкәсендә яшәvче татарлар Булат Солэйманов сызган юллардан тайпылмый, vсешкә омтылып хәрәкәт итә, дип, шагыйрь истәлегенә дан жырлау белән бергә, милли vсеш максатларын да билгеләп vтте. “Без, торл е этник чыгышлы татарлар бердәм халык, безне берләштерә торган әдәби телебез бар,

һәр этник торкеминен vзенчәлекләрен саклау да зур әһәмияткә ия, дип, бердәмлекне ныгыту кирәклегенә аерым

басым ясады Динар әфәнде.

Милли эшләр комитетынын эекке рәисе Воробьев Евгений Михайловичнын котлау cvзләре анын татарларга карата һәрчак жылы караштa булуынын тагын бер чагылышы булып янгырады.  Милли эшләр комитетынын бvгенге рәисе  Чернов Владислав Леонидович татар милли vсешенә Хакимиятнен ярдәме озлексез дәвам итә, дип кvрсәтеп, Соләйманов укуларынын тобәк татарлары vсеше очен әһәмиятле чара булып торуын, татарлар vсешенә vзенен дә ихлас шат

булуын белдерде.

Мәгариф дпартаменты  модире Алексей Райдер татар этномәдәни компонентлы мәктәпләргә карата vзе житәкләгән ведомствонын игътибарлы булуы турында сойләп, татар теле укытучыларынын югары сыйфатлы эш алып баруларына зур канәгатьлек белдерде. Анын

ялкынлы чыгышын бvлеп, жәмәгать эшлеклесе Өнәс Гаитовнын

урыныннан бер cvз - “А язык?!” дип янгыратып, чыгыш ясаучыны сискәндерve остенә, хәл ителмәгән проблемалар барлыгын да искә тошеv омтылышы рәвешендә кабул ителде.

Янәшәсендә утырган бер дәvләт вәкиле яшертен генә

анын кабыргасына тортеп куйды: тик кенә утыр, янәсе.

Туган тел язмышына битараф булмаганнар Өнәснен шушы бер cvзе артында ана телебезнен юкка чыгу куркынычы алдына килеп баскан фажигаи хәлдә торуын

анламый калмагандыр.

Мәгариф башлыгы да белми тvгел, белә

татар теленен нинди хәлдә булуын, әмма Өнәс янгыраткан шелтәне кvнеленә авыр кабул итте,

жавапсыз калмады: “Без дәvләт стандартлары буенча эшлибез, анын кысаларыннан чыга алмыйбыз, ә дәvләт стандартын тогәл vтибез”, - диде. Татар мәктәпләренен

кvпчелеге ябылып, аларда

укыган балларнын урыс мәктәләренә кvчерелгәннән сон туган телне ойрәнv хокукыннан мәхрvм ителvе, калган 48 (90 нчы еллар башындагы 118 мәктәптән) рус мәктәпләренен филиалларына әверелдерелvе,

әнә шул татар этномәдәни колмпонентлы филиалларда да татар теленен елдан-елга факультативка кvчерелә баруы, мәктәпләрдә татар теле кулланышынын кысылганнан-кысыла баруы, әлбәттә, дәvләт стандартлары конкрет таләп иткән нәрсәләр тvгеллеге турында конференция ахырына кадәр тел кузгатучы булмады. “Бәйрәм булгач, бәйрәм булсын!, - дигәндәй...

Минем кvз алдымнан берничә ел элек Алексей Райдер кабинетында анын белән кvзгә-кvз утырып сойләшvебез узды. Бу очрашуны Тубыл районынын Кvкерәнде авылы егете Булат Ташбулатов оештырган иде, ул сойләшvдә, миннән гайре, КПРФ партиясенен Томән олкәсе бvлекчәсе рәисе Тамара Казанцева белән бергә ЛДПР партиясе вәкиле дә бар иде. Алексей Владимирович Райдерга без сазлар, кvлләр арасында утырган Кvкрәнде мәктәбен Кутарбитка мәктәбенә филиал итеп кушмыйча, мостәкыйль мәктәп итеп калдыру vтенече белән кергән идек, гомумән барлык мәктәпләрне дә, зур урта мәктәпләрне дә, филиалга кvчерvгә ризасызлык белдереп,

сvз арасында татар балаларынын туган телне мәктәпләрдә ойрәнvчеләр саны 15 процентка да житми, дип белдереп. Сойләшv барышында мәгариф башлыгы Кvкрәнде мәктәбен мостәкыйль

мәктәп итеп калдыруга омет биргәнг булса да, гамәлдә ул мәктәп филиал булып кына калды. Сонырнан авыл халкы мәктәп директорын канәгатьләндерде

филиал булып калу, дип әйтте. Шунысы кызганыч та: мәктәп директорлары каршылыксыз кvнә кануннарга каршы килгән кысылуларга. Шунысы да аянычлы хәл: Кvкрәнде мәктәбендә балалар саны елдан-елга кими бара, мәктәпнен филиалга әверелдерелvен аклагандай. Эшсезлек нәтижәсендә авылларда яши алмый балалы гаиләләр, шәһәрләргә кvчә, ә шәһәрләребездә бер генә дә тулы канлы татар этномәдәни компонентлы мәктәп юк. Томәндәге 52 нче Кырынкvл мәзктәбе белән Тубылдагы 15 мәктәп – милли составлары катнаш мәктәпләр, алардан, татар балалары туган телне камил белеп чыга алмый, гәрчә татар теле укытучылары танылган кочле укытучылар булса да.

Гафу итегез! Читкә тайпылып киттем.

Котлау сvзе белән Зиннәт хәзрәт чыкты монбәргә, анын чыгышы кvләмле, хисле булды. Торки халыкларнын бердәмлеге тирән тамырлардан килә, без торки халыклар бердәмлегенен дәвамы, торле тобәкләрдә гомер итvче татар этник торкемнәре татар булып формалашканбыз, безнен бер уртак татар әдәби телебез бар, безнен тобәкнен берничә буыны шул телдз белем алды, без аны beləбез, яратабыз, сакларга кирәк аны, дигән фикерен Муса Жәлилнен “Вәхшәт” шигыреннән бер озекне сәнгатьле итеп укып дәлилләде, һәр татарга анлаешлы сvзләр бит болар, дип, әдәби телнен барлык татарларны берләштерә торган уртак тел булуын исбатларга тырышты тобәгебез мофтие. Татар әдәби теленен Себердә сакланырга тиешлеге турында оздереп әйтv Булат Соләйманов укулары очен яналык, бу фикер беренче мәртәбә янгырады, дисәм дә ялгыш булмас.

**Котлаулардан сон докладлар белән чыгышлар башланды**

Докладлар бvлеген Хәнисә Алишина Булат Соләймановка багышланган кvләмле чыгышы белән ачып жибәрде. Булатнын тормышын һәм ижат юлын тирән һәм кин ачты Хәнисә ханым, Казан, Мәскәv архивларыннан тапкан мәгълvматлар белән баетты ул vзенен чыгышын. Ул да Үзенен чыгышында уртак татар әдәби теленен милләтне саклау очен зур әһәмияткә ия булуы турындагы фикерне vз фикере итеп беренче мәртәбә белдерде – бу да тщәсирле булды конференциядә катнашучылар очен: “Мин тел белгече, доресен әйтергә тиешмен, барлык татарлар очен уртак булган бер әдәби тел бар”, - дип, басым ясады ул.

Тубыл шәһәрендә яшәп педагогика академиясендә татар кафедрасын житәкләгән, бvгенге кондә Казан федераль университетында кафедра модире булып хезмәт итvче профессор, филология фәннәре докторы Флера Сәйфуллинанын онлайн-чыгышы Себер язучыларына багышланган иде. Томән жирлеге фән эшлекләре, язучылары белән горурланырга хокуклы, Себер язучылары Булат Соләйманов белән

Габдулла Тукай исемендәге Татарстаннын дәvләт бvләгенә лаек булган Якуб Зәнкиевнен татар әдәбиятында лаеклы урын тотып торулары, Томән жирлегендә татарларга бәйле бик кvп китап басылып чыгуы – Себер татарларынын рухи-мәдәни

байлыгы һәм горурлыгы, дип кvрсәтте Флера ханым.

Булат Соләймановнын дусты, фикердәше, анын исемендәге тобәк премиясе

лауреаты Әнәс Гаитовнын чыгышы “Себер татарларынын мостәйкыйльлеге турында фәнни мәгълvматлар” дип аталды, танылган галимнәрнен фикерләренә таянып, себер татарларынын аерым мостәкыйль халык булуын дәлилләv бурычын vтәде докладчы. Әйтергә кирәк, чыгышы алдыннан шундый кисәтv ясады Әнәс Гаитов: “Минем бу чыгышым уртак татар әдәби телен инкарь итv тvгел”.

Омскидан тарих фәннәре кандидаты, Россия фәннәр академиясе Археология, этнография институтынын Омски филиалы фәнни хезмәткәре Анна Ильинанын онлайн трасляциясе аша тәкъдим иткән чыгышы тулысынча себер татарларынын мостәкыйль халык булуын дәлилләvгә багышланган иде. Анын: “Идел буе татарлары экспансиясе дәвам итә, себер татарлары Идел буе татарлары тарафыннан йотыла” дигән фикерен конференциядә утыручыларнын һә ркайсы да кабул итмәде.

Аннан сон доклвд ясаган тарих фәннәре докторы, БТК Идарәсе “Туган жир” журналынын баш мохәррире, Ботендонья татар конгрессынын вәкиле Дамир Исхаков vзенен чыгышын Анна Ильина сvзләренә карата репликасы белән башлап жибәрде: “Себер татарларын Идел буе татарлары йотмый, гомумән, барлык татарларны, себер татарларын да , Әстерхан татарларын да, Идел буе татарларын да урыс мохите йота”, - диде. Анын чыгышы яна фәнни ачышларга таянып тәкъдим ителvе белән бик тә кызыклы һәм әһәмиятле булды. Чыгышынын исеме vк ачыклады анын фикерләрен: “XV нче гасыр Идел буе татарлары белән себер татарлары багланышларына бәйле бер табышмак”. Торле этник торкемнән булган татарларнын Урта гасырларда ук

vзара тыгыз багланышларда булып, бер торкем татарлардан икенче торкемгә ханнар килеп идарә итvе тарихи чыганаклардан билгеле булуын, барлык татарларнын Алтын Урда кысаларында тыгыз элемтәдә икътисад, мәдәният, гореф-гадәтләр олкәсендә алыш-биреш иткән булуларын, бер уртак тамырлардан жәелгәнлекләрен

яна табылган тарихи чыганакларга таянып кvрсәтте Дамир әфәнде.

Шулай ук Ботендонья татар конгрессы вәкиле булып килгән журналист һәм тарих фәннәре кандидаты Илнар Гарифуллин Башкортостандагы татар-башкорт монәсәбәтләре мисалында хакимият органнарынын этник торкемнәр арасына тыгылуы алар арасында каршылыклар китереп чыгаруын, дошманлык хисләре тудыруын ачыклап кvрсәтте, торле этник торкемнәр арасындагы монәсәбәтләргә сак карарга кирәклекне кисәтте ул. Илнар Гарифуллиннын сvзләрен Томән Милли эшләр комитеты рәи се Владислав Леонидович тыныч кына кичерә алмады, vзенә дә кагылгандай кабул итте. Сvз алып, безнен Хакимият татарларнын этник торкемнәре арасындагы монәсәбәтләргә тыкшынмый, дип,

барлык этник торкемнәргә карата жылы монәсәбәттә булуын белдерде.

Конференоиядә әйтелгән әлеге фикергә бәйле булган хәлләрне читләтеп vтv дорес булмас кебек. Чынында нәкъ менә Томәндә жәмәгать эшчәнлегендә активлык kvрсәткән себер татарлары тарафыннан монда яшәvче казан татарларына карата монәсәбәт, караш дустанә, тыныч кына булмады. Татарлар белән эшләvче оешмалар, учреждениеләр белән себер татарлары гына житәкчелек итәргә тиеш, дигән язылмаган канун чыгарылды, озак кына еллар дәвамында гамәлдә булды һәм әледән-әле калкып чыга

казан татарларына карата

берничә кеше татар жәмгыятенә

таккан бу караш-монәсәбәт, милли vсешне тоткарлап торган сәбәпләрнен берсе дә ул булды.

Кем тудырды ул вәзгыятьне, идарә органнары вәкилләреннән катнашучы булдымы, юкмы бу ыгы-зыгыда... Катнашучы булмаса да, ул каршылыкны

туктату очен хакимият тарафыннан

нәрсәдер

эшләнгәне сизелмәде. Владислав Леонидовичка тидерәсе

килми гаепне: ул яшь кеше, ана вакыт кирәк булды татарлар арасындагы вәзгыятькә тошенv очен. Бу сорауга ачык жавап бирелгәне юк әле, каршылыкны тудыручыларга шелтә булуы да сизелмәде. Хакимият олкә татарлары милли-мәдәни мохтәрияте житәкчеләре

фикеренә генә таянып эш итәргә ярата, ә аларнын фикере kvпчелек фикереме, татарлар очен файдагамы – моны уртага салып карауучы булмады, бvген дә юк – бу бит vзе бер проблема булып тора.

Россия фәннәр академиясенен Тубылдагы комплекслы фәнни станциясе олкән фәнни хезмәткәре Зәйтvнә Тычинскихнын “Томән олкәсендә себер татарлары музеен булдыру проектлары” дип аталган чыгышын катнашучылар жылы кабул иттеләр. Зәйтvнә ханым хәбәр итvенчә, Томәндә “Чимги-Тура”, дип

аталган һәм Тубылда да себер татарлары этнографик музейлар булдыру каралган җәмәгатьчелек тарафыннан. Томәндә Татар мәдәният vзәгеннән ерак тvгел ике катлы бинаны

музей очен әзерләv эшләре

Ботендонья татар конгрессынын Томәндәге

Вәкиллеге житәкчесе Ринат Насыйров карамагында. Зәйтvнә Тычинскихнын музейлар проекты турындагы чыгышы, могаен, конференциянен темасына жавап йозендә бердәнберг гамәли адым – бу проект конференциядә катнашучыларда милли vсеш юнәлешендә якты ометләр уятуы белән

кызыклы булды.

Ахырда Тубыл шагыйрәсе Галия Абайдуллинанын чыгышы жанландырып жибәрде катнашучыларны. Ул инде 25 шигырьләр жыентыгы бастырып чыгарган, алдагы елларда әдәби телдә ижат иткән булса, сонгы вакытларда себертатар телендә язуга кvчкән. Булат Соләймановнын себертатар теленә кvчергән бер шигырен дә укып кvрсәтте Галия ханым.

Олкә хакимияте вәкилләренен ирешелгән унышларга таянып югары рухта котлаулары, Булат Соләймановны тантаналы искә алу бәйрәм рухы, бәйрәм тосе белән бизәде конференцияне. Дуслар белән аралашу пандемия аркасында чикләнгән бу заманда

зарыгып котелгән очрашгулар чынлап та vзе бәхет иде.

Конференциягә ерак тобәкләрдән дә дәрәжәле галимнәрдән кvп кенә докладлар килгән – Мәскәvдән, Санкт-Петербургтан, Торкиядән, Казаннан, Омскидан,

Уфадан, Яр-Чаллыдан, Томән-Тубыл галимнәреннән. Барлык докладлар да конференция жыентыгында урын алачак, диделәр.

Булып vткән конференция турында аны оештыру коммиссиясенен житәкчесе Динар Абукин белән фкерләребез белән уртаклаштык. “Конференцияне оештыру комиссиясе планлаштырган проект гамәлгә ашты, мин бигрәк тә галимнәр белән аралашып, аларны чакырган Хәбибә Садыйр кызы Шагбановага

рәхмәтлемен, Соләйманов укуларын башлап

оештырып гамәлгә керткәннәрнен берсе

Рифкать Насыйбуллиннын ярдәме зур булды. Безнен алда татарларны оч телле – татар әдәби телле, себертатар телле, рус телле – итv, тарихны, туган як табигатен ойрәнv максатларын кvз унаенда тотабыз, аларны гамәлгә ашыру очен дәреслекләр, әсбаплар, китаплар бастырып чыгарырга кирәк, конференциядә бу мәсьәләләр

каралмады. Минем карашымча, бу максатларга ирешv юлларын

халык белән бергә, галимнәр, экспертлар, практик укытучылар белән кинәшеп хәл итәргә кирәк”, - дип уртаклашты конференциягә бәйле фикерләшре белән Динар Абукин.

Мин конференциядә утырган, аны тынлаган, кvзәткән кешеләрнен дә фикерләре белән кызыксындым. “Ярарлык. Аннан артык була алмас Соләйманов укулары, чонки бернәрсәне дә vзгәртеп булмый хәзер”, -

дип, саклык белдереп

әйтvчеләр булды.

Конференция темасынын ачыкланмый калуы анын ашыгыч оештырылып vткәрелvендә, дигән фикер туды.

Торле темаларга чыгышлар янгырады, әмма конференциянен концепциясе эшләнелмәгәнлеге кvренеп чыкты. Концепциясен тозеп, конференцияне анын нигезендә vткәрv очен вакыт кvп кирәк,кимендә бер ел.Тарихта беренче мәртәбә әдәби телне дә сакларга кирәклеге турында әйтелде, югыйсә алдагы “Соләйманов укулары”нда себер теле турында гына була иде сvз, сонгы елларда беренче Соләйманов укулары билгеләгән максатлардан читкә китеп кенә vткәрелә иде конференция. Бусы топ юлга борылу омтылышы белән vткәрелде, әмма темада билгеләнгән туган телне, мәдәниятне vстерv момкинлекләре ачыкланмады.

Әдәби телне саклау кирәклеге турында әйтелсә дә,

себертатар телен, әдәби телне ничек итеп саклап vстерv, аерым-аерыммы, әллә бергәме – хәтта шунын турында да

сvз булмады.

Анын очен тобәктә себертатар теленен һәм

әдәби телнен торышы турында тирән, топле анализ ясарга кирәк, андый анализ булмады конференциядә, телләрнен гамәли торышы ачыкланмады, гәрчә телләрне саклау идеясе янгыраса да. Гомумән, милли vсешкә бәйле бернинди проблема ачыкланмады. Конференциягә килгәннәргә фикер алышырга вакыт калмады, кvп вакыт котлау сvзләре белән йотылды. Йомгак ясалмады, резолюция кабул ителмәде. Конференциягә тәкъдим ителгән, ләкин янгырамаган докладларнын темалары кызыклы кvренә,

себер татарлары тарихына, мәдәнияте, тел vзенчәлекләренә багышланган темалар кvп, әмма әдәби, себертатар телләренен торышларын, аларнын һәркайсынын ролен, vсеш юлларын ачыклаган

темалар кvренмәде жыентыкка керәчәк ул докладлар арасында.

Миндә Булат Соләйманов укулары кысаларында vткәрелгән фәнни-гамәли конференция жыентыкларынын тупламасы саклана. Аларны ачкалап укыйм да, гажәпкә калам: нинди кызыклы, фәнни докладлар бар аларда, ә менә милли vсеш проблемаларын тормышта хәл итv юлларын кvрсәткәннәре юк, бигрәк тә

тел мәсьәләләре декларатив тостә генә билгеләнеп барылган икән, докладлар арасында конференция темасына караганнары аз, галимнәр vзләрен кызыксындырган темаларга язылган докладларын тәкъдим итеп барганнар. Ә вакыт узган да узган, vтеп киткән...

Конференцияләр милли vсешкә этәргеч кочкә әверелсен очен аларнын темасы ачык билгеләнгән булырга, чыгышлар шул темага бәйле булырга тиеш, аларда фән белән гамәлилек балансы сакланырга, алга таба милли vсеш юллары ачык билгеләнеп каралырга тиеш,  дигән фикер туды конференоиядә катнашучылар арасында.

Бибинур САБИРОВА